ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1051 24.06.2025

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләр куллананы (фейерверк атуны) тәртипкә салу чаралары турында» 2021 елның 10 декабрендәге 1710 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карарының 56 пункты нигезендә, Яр Чаллы шәһәре Кама транспорт прокуратурасының протестын караганнан соң Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләр куллананы (фейерверк атуны) тәртипкә салу чаралары турында» 2021 елның 10 декабрендәге 1710 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) 50 метрдан артык биеклеккә күтәрелеш булган салют һәм фейерверклар үткәргәндә Бердәм система үзәкләреннән һава киңлегеннән файдалануга, шулай ук салют һәм фейерверкларның биеклегенә бәйсез рәвештә җир яки су өслегенә һава алымнары полосалары проекциясенең чикләренә рөхсәт алу өчен кирәкле документлар тапшырылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева